| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК | ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е　　　　　　　　　　К А Р А Р

2022 елның «28» гыйнвары　　　Лениногорск ш.　　　№3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль Закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә 6 964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәрен муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма

комитетының 2021 елның 29 гыйнварындагы 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар 2022 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.А. Мөхәмәтшинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Сытдиков

Л.В.Лапицкая
5-13-74

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәрендә
җирләү буенча (туганнары булганнар) хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе
2022 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 632,66 |
| 3. Мәрхүмнең гаүдәсен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 323,28 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 3 008,74 |
| Барлыгы | **6 964,68** |

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәрендә
җирләү буенча (туганнары булмаганнар) хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
бәясе 2022 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетнең тәнен урау | 868,78 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 763,88 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1 323,28 |
| 5. Кабер казу һәм җирләү | 3 008,74 |
| Барлыгы | **6 964,68** |

___________________________________